РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 23 марты № 22

Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 26 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү мәсьәләсен җайга салу максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Түбән Кама шәһәре Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 26 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Конкурста катнашырга Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба - гражданнар), шулай ук муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче һәм әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында каралган срокта әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырган муниципаль хезмәткәрләргә рөхсәт ителә.

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5. Гражданга (муниципаль хезмәткәргә) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәүгә бәйле, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашырга рөхсәт ителми.».

1.3. 9 пунктның 1, 4, 6 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны фото белән;

4) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы);

6) конкурсны үткәрү елына кадәрге ел өчен керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат;».

1.4. 13 пунктта беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Документлар гражданнарга (муниципаль хезмәткәрләргә) шәхсән,

почта аша яисә электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасын кулланып тапшырыла.»

1.5. 21 пунктта өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.».

1.6. 25 пунктка түбәндәге редакциядә беренче абзац өстәргә: «Кандидатлар булмаса яисә вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс гамәлгә ашмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип, язмача хәбәр ителә.».

1.7. 26 пунктны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырса, конкурс нәтиҗәләре аңа электрон документ рәвешендә җибәрелә.».

1.8. 27 пунктка түбәндәге редакциядә җөмлә өстәргә: «Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә бирелгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин